КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ӨРКЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

2023 нче елның 18 нче декабереннән №31

Өркеш авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 нче апреленнән 5 нче номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Өркеш авылы җирлеге Советы карар бирде:

1. Өркеш авылы җирлеге Советының 2018 елның 27 нче апреленнән 5 нче номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Өркеш авылы җирлегенең муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 31 октябрендәге 23 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 4 номерлы, 2020 елның 19 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 4 номерлы, 2022 елның 15 июлендәге 8 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 4 номерлы, 2023 елның 30 нчы октябереннән 25 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Өркеш авыл җирлеге башлыгына классны чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы : А.Ш. Әгъләмова